ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 09 » июнь 2016 ел** **№ 661**

**Хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү өчен урыннар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 ст.1, 50 ч.1 ст. һәм Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 ст.1, 39 ч.1 ст. нигезендә Арча районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Хөкем ителгәннәргә төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү өчен Арча муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында беркетелгән исемлекне расларга.

2. Төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәтү өчен төп эш урыны булмаган хөкем ителгәннәр тарафыннан беркетелгән урыннар исемлеген расларга.

3. Төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәтү өчен төп эш урыны булмаган хөкем ителгәннәр тарафыннан билгеләнгән оешмалар житәкчеләренә хөкем ителгәннәрне төзәтү эшләренә урнаштыру һәм мәҗбүри эшләр белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы буенча Росси УФСИН Идарәсенең Арча районы буенча филиалына (Сәлахетдинов А.Д.) хөкем ителгәннәрне әлеге карар белән билгеләнгән урыннарга төзәтү һәм мәҗбүри эшләргә җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. «Төзәтү һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәза үтәтү өчен урыннар билгеләү турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 03 мартындагы 235 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район башкарма комитеты житәкчесе урынбасары Р.И. Гарифжановка йөкләргә.

Башкарма комитет житәкчесе И.О.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«09» 06 2016 ел, № 661
карары белән
**РАСЛАНДЫ**

**Арча муниципаль районы составына керүче җирле үзидарә органнарында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри эшләр һәм җирлекләр исемлеге**

| № т/б | Авыл җирлекләре исемнәре | Эшләр төрләре |
|---|---|---|
| 1. | Апаз авыл җирлеге | - шәһәрне һәм авыл җирлекләрен төзекләндерү буенча ярдәмче эшләр;<br>- территорияләрне җыештыру;<br>- ярдәмче эшләр. |
| 2. | Кәче авыл җирлеге | |
| 3. | Наласа авыл җирлеге | |
| 4. | Яңа Кишет авыл җирлеге | |
| 5. | Яңа Кырлай авыл җирлеге | |
| 6. | Яңа Кенәр авыл җирлеге | |
| 7. | Урта Курса авыл җирлеге | |
| 8. | Иске Кырлай авыл җирлеге | |
| 9. | Иске Чүриле авыл җирлеге | |
| 10. | Урта Аты авыл җирлеге | |
| 11. | Сеҗе авыл җирлеге | |
| 12. | Ташкичү авыл җирлеге | |
| 13. | Үрнәк авыл җирлеге | |
| 14. | Утар Аты авыл җирлеге | |
| 15. | Шушмабаш авыл җирлеге | |
| 16. | Яңасала авыл җирлеге | |
| 17. | "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге | |

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«09» 06 2016 ел, № 661
карары белән
**РАСЛАНДЫ**

**Төп эш урыны булмаган тоткыннар тарафыннан төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәтү урыннары исемлеге**

| № т/б | Оешмаларның аталышы | Эшләр төрләре |
|---|---|---|
| 1. | «Жилкомбытсервис» ҖЧҖ | - ярдәмче эшләр;<br>- территорияләрне җыештыру |
| 2. | «Арча КСМ» ҖЧҖ | |
| 3. | «Арча МСО» ҖЧҖ | |
| 4. | "Энергосервис" ААҖ | |